**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 ел, 29 декабрь** **№ 90**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 нче декабрендәге 97 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының муниципаль хезмәткәрләре һәм аларның вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән акчаларны кабул итүне хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи хәлләренә яисә алар тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән акчаларны күчерү турындагы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 нче декабрендәге 97 нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм Балтач авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи хәлләренә яисә алар тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, аны гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән

акчаларны кабул итү турында хәбәр итү тәртибе” нигезләмәсенә үзгәреш кертергә:

1) Нигезләмәнең 2 пунктындагы икенче абзацында «хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләрен " хәлиткеч тавыш хокукы белән даими (штат) нигездә , комиссиядә эшләүче " сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балтач авылы, Мэктэп ур., 1;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балтач авылы, Мэктэп ур., 2,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы<br>
Кама Тамагы муниципаль районы<br>
Балтачавыл җирлеге башлыгы,<br>
Татарстан Республикасы<br>
Кама Тамагы муниципаль районы<br>
Балтач авыл җирлеге Советы рәисе Д.И. Мухамадуллин